2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә” муниципаль берәмлегенең Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсендә гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17 ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә” муниципаль берәмлегенең Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә” муниципаль берәмлегенең Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау, вак таш җәю, юлларга асфальт салу); урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычларны алыштыру һәм сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен төзү); традицион күмү урыннарын төзекләндерү (дератизация, куакларны кисү, печән чабу) өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы В.Н. Сенин